СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 298

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы карары белән ( Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 145 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясенең Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы карары белән ( Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 145 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 1.2. пунктында «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «,Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы закон белән» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 1.2. пунктында түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга таләпләр»;

2. Әлеге карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми Порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**